ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**Постановление** **Карар**

№ 291 от «19» 08 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының 2025 елның
25 декабрендәге “2026 елда Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында балалар һәм яшьләр
ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында”
512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2026 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципального района Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 25 декабрендәге “2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру турында” 512 номерлы карарына (алга таба-Программа) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен тәэмин итү программасының 2 бүлеге 1 юлның 15 нче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2. ӘЛЕГЕ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА РАСЛАНГАН
ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ КҮЛӘМЕ НОРМАТИВЛАРЫ

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Интеллект» «Сафари Тент» палаткалы лагерьларда профиль сменаларын оештыру | июль-август | 7 | 210 | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” МКУ |

0000013432

1.2. 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү программасының 3 бүлеге 1 багана 2 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. ПАЛАТКАЛЫ ЛАГЕРЬДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАНЫ ОЕШТЫРУ

| **Палаткалы лагерь исеме** | **Үткәрү урыны** | **Кеше саны*** | **Көн саны*** | **Юлламаның норматив бәясе мең сумнарда** | **Бюджеттан субсидияләр ** мең сумнарда** | **Ата-аналар взносы** мең сумнарда** | **Башка акчалар (предприятиеләр, җирле бюджет) мең сум.** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Интеллект» палаткалы профильле лагерь | Мамадыш районы, Татарстан Республикасы | 210 | 7 | 13,53 | 11,50 | 2,03 | 0,00 |
| «Сафари Тент» «Кама» ОДУЛ МБУ | Соколка ав., Мамадыш районы, Татарстан Республикасы | | | | | | |
| Профилактик исәптә торучы балалар өчен “Дети галактики”профильле махсуслаштырылган лагерь | Мамадыш районы, Татарстан Республикасы | 30 | 7 | 13,53 | 13,53 | 0,00 | 0,00 |

»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru сайтында,Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М. Ефимов